КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 июль г.Казань № 886

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 128 нче, 2013 ел, 7 ноябрь, 860 нчы, 2015 ел, 26 август, 623 нче, 2016 ел, 17 октябрь, 749 нчы, 2016 ел, 31 октябрь, 800 нче, 2017 ел, 10 май, 269 нчы, 2018 ел, 30 июль, 613 нче, 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче, 2018 ел, 19 декабрь, 1179 нчы, 2018 ел, 29 декабрь, 1302 нче, 2019 ел, 13 июль, 577 нче, 2019 ел, 19 ноябрь, 1057 нче, 2020 ел, 6 март, 178 нче, 2020 ел, 19 май, 405 нче, 2020 ел, 2 июнь, 458 нче, 2021 ел, 10 апрель, 238 нче, 2022 ел, 10 май, 427 нче, 2022 ел, 05 декабрь, 1281 нче, 2023 ел, 25 гыйнвар, 40 нчы, 2023 ел, 3 март, 205 нче, 2023 ел, 20 май, 616 нчы, 2023 ел, 22 май, 626 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминиятләштерүе турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминиятләштерүе турында» Федераль закон кабул ителү белән бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 29 ноябрендәге 313-ФЗ номерлы федераль законнарның аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыруны тәэмин итү чаралары турында»

2011 елның 25 августындагы ПУ-525 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары, оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 май, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.»;

3.3 пунктта:

3.3.52 пунктчада «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.53 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле башкарма органына» сүзләрен «тиешле республика башкарма хакимият органына» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның унберенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктның утыз беренче абзацында «министрлыклар, ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга, «предприятиеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.3 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин